ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 03 2023 г. № 261

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урынны файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясына ярашлы рәвештә, Россия Төзелеш Министрлыгының 2023 елның 13 гыйнварындагы 18/пр номерлы «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгы белән расланган социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәреш кертү турында» боерыгына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урынны файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

Нигезләмәнең 1 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын наемга алу өчен түләү күләме тәңгәллеге коэффициенты зурлыгы - 0,057 күләмендә, дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын наемга алу өчен 0,057 күләмендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкченең беренче урынбасары И.И. Мөхәммәтҗанов